РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**11.04.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№21/3**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре Советының
2019 елның 19 сентябрендәге
“Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
милкендәге муниципаль мөлкәтне
хосусыйлаштыру Тәртибен раслау
турында”гы 38/1 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 2019 елның 19 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Тәртибен раслау турында”гы 38/1 номерлы карарына (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 2020елның 28 октябрендәге 3/3 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 19/2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Тәртипнең 1.9 пунктын яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«1.9. Арендалана торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруда кече һәм урта эшкуарлык субъектларының катнашу үзенчәлекләре федераль закон һәм муниципаль норматив-хокукый актлар белән билгеләнергә мөмкин».

2. Әлеге карарны «Чистопольские известия» газетасында яки Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутатлык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре Башлыгы Д.А. Иванов